Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

«12» ноябрь, 2021 ел № 35

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башлыгының 2021 елның 20 октябрендәге 993 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощак авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2021 елның 08 июлендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кощаково авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Кощаково авыл җирлеге башлыгы З.Н. Саттарова